**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

“20” декабрь 2018 нче ел № 601

**«Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге чикләрендә урнашкан «Архангел ятмаларын үзле нефтьтән кутәру " линия объектына территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты өчен документларны раслау хакында карар кабул итү харында»**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары нигезендә, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Бәяләмәне исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә "Архангел ятмаларын үзле нефтьтән кутәру” - В.Д.Шашин исемендәге “Татнефть” ГАҖ объекты проектлау һәм төзү өчен территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты составында территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документацияне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы** **Р.Р. Фәсахов**